КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 9 сентябрь г.Казань № 804

«Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе эшчәнлеген тәэмин итү идарәсе» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесен оештыру турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең «Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе эшчәнлеген тәэмин итү идарәсе» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесен (алга таба – казна учреждениесе) оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләр дип билгеләргә:

казна учреждениесен гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе гамәлгә ашыра;

казна учреждениесе хезмәткәрләренең иң чик штат саны 35 берәмлек тәшкил итә;

казна учреждениесе эшчәнлеген финанслар белән тәэмин итү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законында «Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе» ведомствосы буенча күздә тотылган акча исәбеннән бюджет сметасы нигезендә гамәлгә ашырыла;

казна учреждениесе эшчәнлегенең максаты – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында Дәүләт торак күзәтчелеге турында» 2011 ел, 26 декабрь, 1068 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе турындагы нигезләмә белән билгеләнгән төбәк дәүләт торак күзәтчелеге һәм лицензия контроле функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өлкәсендә Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе эшчәнлегенә оештыру-техник, методик, мәгълүмати ярдәм һәм эксперт ярдәме күрсәтүне тәэмин итү.

3. Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә:

бу карар кабул ителгән көннән 30 көн эчендә казна учреждениесе уставы проектын эшләргә, аны Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына, «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Татарстан Республикасының Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә килештерүгә җибәрергә һәм килештергәннән соң уставны расларга;

30 көн эчендә структурасын, штат расписаниесен, оештырылган казна учреждениесен дәүләт теркәвенә алуны килештерүне тәэмин итәргә, җитәкчесен билгеләргә һәм аның белән хезмәт шартнамәсен төзергә;

казна учреждениесен дәүләт теркәвенә алган көннән 30 көн эчендә Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Зур Кызыл урамы, 15/9 нчы йорт адресы буенча урнашкан казна учреждениесе эшчәнлеген тәэмин итү өчен кирәкле мөлкәт исемлеген (алга таба – исемлек), шулай ук күчемсез мөлкәт объектларына техник документларны Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына кертергә.

4. Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгына:

мөлкәт исемлеге Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан кертелгәннән соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Зур Кызыл урамы, 15/9 нчы йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен исемлек нигезендә оператив идарә хокукында казна учреждениесенә беркетергә;

120 көн эчендә Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Зур Кызыл урамы, 15/9 нчы йорт адресы буенча урнашкан, исемлеккә кертелгән күчемсез мөлкәт объекты урнашкан җир кишәрлеген казна учреждениесенә даими (чикләнмәгән вакытта) файдалану хокукына бирүне тәэмин итәргә.

5. «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы Икътисадый һәм социаль тикшеренүләр үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә, бу карар кабул ителүгә бәйле рәвештә, 30 көн эчендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына Татарстан Республикасының тиешле норматив хокукый актларына үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр кертергә.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин